**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында
2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

15 ноябрь 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы 2022 елның 24 ноябре № 1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында халык җыены

**карары:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган зат , I һәм II группа инвалидларыннан, ел дәвамында җирлек территориясендә яшәмәүче гражданнардан (студентлар; РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче затлар, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар; хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзалары (социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр, янгыннан зыян күрүчеләрдән) тыш, 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Яңа Әхмәт торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Яңа Әхмәт торак пунктында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3) Яңа Әхмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Советы Башлыгы ___________ Ф.М.Хөснуллин
(имза)